**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**«Малоелгинская средняя общеобразовательная школа»**
**Лаишевского муниципального района Республики Татарстан**

| **РАССМОТРЕНО** | **СОГЛАСОВАНО** | **УТВЕРЖДЕНО** |
|---|---|---|
| руководитель МО МБОУ "Малоелгинская СОШ" | Заместитель директора по ВР "Малоелгинская СОШ" | Директор школы МБОУ "Малоелгинская СОШ" |
| ____________Хисамова А.М. | ___________Киямова С. М. | __________Валиуллин М.К. |
| Протокол № 1 | Протокол № 1 | Приказ № 80 |
| от 28.08.2025 г. | от 28.08.2025 г. | от 28.08.2025 г. |

МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "МАЛОЕЛГИНСКАЯ СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА" ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Подписано цифровой подписью: МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "МАЛОЕЛГИНСКАЯ СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА" ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

## КУРСА ВНЕУРОЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ

## «Сохраним традиции своего народа»

## Направление: общеинтеллектуальное

**10 класс**

**Составитель:** Сунгатова Гулуса Миннулловна

2025

**Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлек программасын үзләштерүе буенча көтелгән нәтиҗәләр:**

**Укучы үзләштерергә тиеш:**

- үзенең шәҗәрәсен, әти-әнисенең, әби-бабасының тормыш юлын;
- үз авылыңның, үз туган ягыңның гореф-гадәтләрен, йола бәйрәмнәрен;
- татар халкының асыл сыйфатларын;
- үз туган ягыңның мәдәни-тарихи культурасын;
- үз авылыңның, үз туган ягыңның халык авыз иҗатын;
- гореф-гадәтләрне, ядкярьләрне саклау – яшьләрнең бик әһәмиятле бурычы;
- олы буын кешеләре янында, музейда үзеңне тоту кагыйдәләрен;

**Укучы эшли белергә тиеш:**

- үзенең шәҗәрәсен;
- мәктәп музее материаллары белән эшли белергә;
- үз авылының, үз туган ягының гореф-гадәтләре, йола бәйрәмнәре турында сөйли белергә;
- авылның халык авыз иҗаты турында сөйли белергә;
- музейда чыгыш ясый белергә.

**Эшчәнлекнең нәтиҗәсе:**

- Укучыларны дәрестән тыш эшчәнлеккә тартып, аларның активлыгын үстерү.
- Мәктәп, район, республика, Россия күләмендә оештырыла торган интелектуаль уен, конкурсларда, проектларда актив катнашу.
- Балалар арасындагы дуслык, бердәмлек, коллективта үз – үзеңне тотуның югары мөмкинлекләренә ирешү.
- “Кече Елга халык авыз иҗаты ,бәетләре” фәнни эшенең тулыландырылган варианты - проект..

**Программаны тормышка ашыру шартлары:**

- Каралган барлык теоретик материалны өйрәнү һәм барлык практик шөгыльне үтәү.
- Һәр балага индивидуаль якын килү, һәр балага шәхес итеп карау.
- Барлык дидактик материалдан һәм информацион - коммуникатив технология чараларыннан файдалану.
- Авыл музее материалларыннан һәм экспонатлардан файдалану.

**Эшчәнлекнең форма һәм методлары:**

- укучылар белән әңгәмәләр;
- бәетләр мөнәҗәтләр, җыр-такмаклар тыңлау;
- тарихи күзәтүләр, экскурсияләр;
- иртәләр, викториналар, конкурс, төрле ярышлар;
- рольле, хәрәкәтле , халкыбызның җырлы – биюле уеннар;
- сәхнәләштерелгән әкиятләр;
- китап укучылар конференциясе;
- анкеталар; тестлар;
- бәйрәмнәр;
- өлкән буын кешеләре белән очрашулар.

- иҗади биремнәр үтәү: альбомга материаллар туплау, фотоальбом, реферат, сочинение, рәсем, әвәләү, төрле темаларга зур булмаган телдән журнал әзерләү, газета чыгару
- махсус әдәбият өйрәнү,музей материаллары белән танышу, җирле газета материаллары белән танышу
- җыелган материаллардан музейда экспозицияләр оештыру;
- эзләнү-тикшеренү эшен оештыру (материал җыю);
- авыл, район картасы белән эшләү;
- музейда экскурсияләр алып бару;
- проект эше башкару.

**“Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклыйбыз” дәрестән тыш эшчәнлек** 34 сәгатькә исәпләнгән һәм 6-8 нче сыйныф укучылары өчен төзелгән. Эчтәлеге Лаеш һәм Кече Елга төбәгенә караган милли-төбәк компонентларын иңләп ала.

**Эчтәлек**

**I бүлек Халкыбызның асыл сыйфатлары (9 сәг)**

Кереш. “Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклыйбыз” дәрестән тыш эшчәнлекнең максаты һәм бурычлары.(1сәг)
Халкыбызның асыл сыйфатлары. (1сәг)
Намуслылык, тыйнаклык, ярдәмчеллек- татар халкының асыл сыйфаты. Авыл тормышыннан мисаллар китерү. (1сәг)
Кунакчыллык, юмартлык. Кунакны безнең халык ничек сыйлый? Татар халкының милли ашлары. (1сәг)
Кыюлык, батырлык- татар егетләрен аерып торган сыйфат. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм әфган,чечня сугышында катнашкан якташларыбыз мисалында фикерне дәлилләү. (1сәг)
Тәмле телле булсаң, сөярләр. Тәмле теллелек- халкымның сөйләм бизәге. Туганнарны нинди матур сүзләр белән атап була? (1сәг)
Динле булу-иманлы булу ул. Мөселман кешесе үтәргә тиеш кагыйдәләр. (1сәг)
Туган җанлылык – татарның төп сыйфаты. Туганнарсыз җирдә яшәп булмый. Син туганнарыңны беләсеңме?. (1сәг)
Һөнәрчелек, кәсепчелек- халкымның төп сыйфаты. Зәрканчылык, итек басу, чигү, балта остасы, умартачылык кебек һөнәрләр әле дә яши. (1сәг)

**II бүлек. Татар халкының гореф-гадәтләре (5 сәг)**

Ата-ананы, әби-бабаны хөрмәт итү- төп канун. Гаиләдә баш кеше- ата. Олыларның урыны –түрдә. Аналарга хөрмәт – оҗмах ачкычы. (1сәг)
Татар йорты еравктан ук балкып тора. Татарлар элек-электән йортларын төзек, чиста тотканнар. Матур бизәкле тәрәзә йөзлекләре. (1сәг)
Өмәләр- халкыбызның бердәмлеген күрсәтүче гореф-гадәт. Өмәләрнең төрләре: өй күтәрү өмәсе, тула өмәсе, печән өмәсе, ашлык сугу өмәсе, терлек чалу өмәсе, киндер сугу өмәсе һ.б. Кайсы өмәләр хәзер дә яши? (1сәг)
Кич утыру- күркәм гадәт. “Шәл бәйләдем...” Кул эшләренә кызлар кич утырганда өйрәнгән. (1сәг)
“Кунак кызлар килгән утырмага...”(Г.Бәширов) Хәзер кызлар утырмага киләме? (1сәг)

**III бүлек. Кеше гомере белән бәйле йолалар (7 сәг)**

Бәби туу- иң шатлыклы вакыйга. Бәбигә исем куштыру. Бәби ашы китерү- күркәм гадәт. (1сәг)
Сөннәткә утырту-ир балалар өчен мәҗбүри йола. (1сәг)
Туй йолалары һәр якныкы үзенчә. Никах туе. Никахтан башка яшәргә ярыймы? (1сәг)
Туган көн бәйрәмнәре. Эчемлек кулланырга кирәкме? (1сәг)
Кешене соңгы юлга озату. Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел. (1сәг)
Дини бәйрәмнәр: Ураза гаете, Корбан гаете, Кадер кичәсе, Рамазан ае һ.б. (1сәг)

Керәшен халкының Пасха, Троица һ.б. бәйрәмнәре. Ташкирмән авылында алар ничек үткәрелә? (1сәг)

## IV бүлек. Халкыбызның йола бәйрәмнәре (6сәг)

Сабантуй – татар халкының иң күңелле хесмәт бәйрәме, миллләтнең йөзек кашы. (1сәг)
Каз өмәсе- уңганлык, җитезлек бәйгесе ул . Хәзер Каз өмәләре үткәреләме? (1сәг)
Нардуган- керәшен халык бәйрәме (1сәг)
Нәүрүз – язгы күркәм бәйрәм, төркиләрнең Яңа ел бәйрәме. Безнең мәктәптә ул ничек уза?(1сәг)
Карга боткасы. Май чабу. Алар хәзер уздырыламы? (1сәг)
Сөмбелә- көзге уңыш бәйрәме. Безнең мәктәптә ничек уза? (1сәг)

## V бүлек. Кече Елга авылының халык авыз ижаты(4 сәг)

Кече Елга бәетләре. Булган бәетләр белән танышу. Яңаларын алып килү һәм уку. (1сәг)
Кече Елга авылы җырлары һәм такмаклары. Бишек җырлары. Мөнәҗәтләр. (1сәг)
Керәшен халык җырлары. Казанбаева Мария башкаруында керәшен халык җырларын тыңлау. (1сәг)
Кече Елга һәм Олы Елга турында риваятьләр. (1сәг)

## VI бүлек. Шәҗәрә төзибез (3 сәг)

“ Буыннарны бәйләп торган нәсел җебем өзелмәсме?!” Шәҗәрәңне беләсеңме? (1сәг)
Укучыларның нәсел шәҗәрәсе белән танышу. (1сәг)
Проект яклау: “Кече Елга авылы гореф-гадәтләре һәм йола бәйрәмнәре” темасына татарча проект (2 төркем) Йомгаклау. “Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклыйбыз” дәрестән тыш эшчәнлеге миңа нәрсә бирде ? (1сәг)

## Календарь-тематик план

| № п/п | Бүлек һәм темалар | Форма организации | Вид деятельности |
|---|---|---|---|
| | **I бүлек Халкыбызның асыл сыйфатлары (9 сәг)** | | |
| 1 | Кереш. “Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклыйбыз” дәрестән тыш эшчәнлегенең максаты һәм бурычлары. | түгәрәк өстәл | уен |
| 2 | Халкыбызның асыл сыйфатлары | түгәрәк өст әл | әңгәмә |
| 3 | Намуслылык, тыйнаклык, ярдәмчеллек- татар халкының асыл сыйфаты. Авыл тормышыннан мисаллар китерү. | факультатив | экскурсия |
| 4 | Кунакчыллык, юмартлык. Кунакны безнең халык ничек сыйлый? Татар халкының милли ашлары. | ярыш | уен |
| 5 | Кыюлык, батырлык- татар егетләрен аерып торган сыйфат. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм Әфганстанда хезмәт иткән егетләребез мисалында фикерне дәлилләү. | очрашу | анкета |
| 6 | Тәмле телле булсаң, сөярләр. Тәмле теллелек- халкымның сөйләм бизәге. Туганнарны нинди матур сүзләр белән атап була? | дискуссия | уен |
| 7 | Динле булу - иманлы булу ул. Мөселман кешесе үтәргә тиеш кагыйдәләр. | лекция | уен |
| 8 | Туган җанлылык – татарның төп сыйфаты. Туганнарсыз җирдә | конкурс | рәсем ясау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яшәп булмый. Син туганнарыңны беләсеңме? | | |
| 9 | Һөнәрчелек, кәсепчелек- халкымның төп сыйфаты. Зәрканчылык, итек басу, чигү, балта остасы, умартачылык кебек һөнәрләр әле дә яши. | лекция | “ Татар халкының гореф-гадәтләре буенча |
| | **II бүлек. Татар халкының гореф-гадәтләре (5 сәг)** | | |
| 10 | Ата-ананы, әби-бабаны хөрмәт итү- төп канун. Гаиләдә баш кеше- ата. Олыларның урыны –түрдә. Аналарга хөрмәт – оҗмах ачкычы. | сәхнәләштерелгән әкият | уен |
| 11 | Татар йорты ерактан ук балкып тора. Татарлар элек-электән йортларын төзек, чиста тотканнар. Матур бизәкле тәрәзә йөзлекләре. | авыл буенча сәяхәт | экскурсия |
| 12 | Өмәләр- халкыбызның бердәмлеген күрсәтүче гореф-гадәт. Өмәләрнең төрләре: өй күтәрү өмәсе, тула өмәсе, печән өмәсе, ашлык сугу өмәсе, терлек чалу өмәсе, киндер сугу өмәсе һ.б. Кайсы өмәләр хәзер дә яши? | әңгәмә | Г.Бәширов “Туган ягым-яшел бишек әсәрен уку |
| 13 | Кич утыру- күркәм гадәт. “Шәл бәйләдем...” Кул эшләренә кызлар кич утырганда өйрәнгән. | җыр өйрәнү | уен |
| 14 | “Кунак кызлар килгән утырмага...”(Г.Бәширов) Хәзер кызлар утырмага киләме? | викторина | тест |
| | **III бүлек. Кеше гомере белән бәйле йолалар (7сәг)** | | |
| 15 | Бәби туу- иң шатлыклы вакыйга. Бәбигә исем куштыру. Бәби ашы китерү- күркәм гадәт. | викторина | тест |
| 16 | Сөннәткә утырту-ир балалар өчен мәҗбүри йола. | әңгәмә | уен |
| 17 | Туй йолалары һәр якныкы үзенчә. Никах туе. Никахтан башка яшәргә ярыймы? | әңгәмә | тест |
| 18 | Туган көн бәйрәмнәре. Эчемлек кулланырга кирәкме? | әңгәмә | Видеоролик карау |
| 19 | Кешене соңгы юлга озату. Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел. | әңгәмә | әңгәмә |
| 20 | Дини бәйрәмнәр: Ураза гаете, Корбан гаете, Кадер кичәсе, Рамазан ае һ.б. | викторина | тест |
| 21 | Керәшен халкының Пасха, Троица һ.б. бәйрәмнәре. | әңгәмә | тест |
| | **IV бүлек. Халкыбызның йола бәйрәмнәре (6сәг)** | | |
| 22 | Сабантуй – татар халкының иң күңелле хезмәт бәйрәме, милләтнең йөзек кашы. | Телдән журнал | экскурсия |
| 23 | Каз өмәсе- уңганлык, җитезлек бәйгесе ул . Хәзер Каз өмәләре | әдәби әсәрләрдән өзекләр | уен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үткәреләме? | | |
| **24** | Нардуган- керәшен халык бәйрәме. | видеодан өзек карау | уен |
| **25** | Нәүрүз – язгы күркәм бәйрәм, төркиләрнең Яңа ел бәйрәме. Безнең мәктәптә ул ничек уза? | уен | тест |
| **26** | Карга боткасы. Май чабу. Алар хәзер уздырыламы? | видеодан өзек карау | тест |
| **27** | Сөмбелә- көзге уңыш бәйрәме. Безнең мәктәптә ничек уза? | телдән журнал | уен |
| | **V бүлек. Кече Елга һәм Олы Елга авылларының халык авыз иҗаты(4 сәг)** | | |
| **28** | Кече Елга бәетләре. Булган бәетләр белән танышу. Яңаларын алып килү һәм уку. | телдән журнал | экскурсия |
| **29** | Кече Елга авылы җырлары һәм такмаклары. Бишек җырлары. Мөнәҗәтләр. | телдән журнал | клуб |
| **30** | Керәшен халык җырлары. Казанбаева Мария башкаруында керәшен халык җырларын тыңлау. | Керәшен халык җырларын тыңлау. | клуб |
| **31** | Кече Елга һәм Олы Елга турында риваятьләр. | материал җыю | конфер. |
| | **VI бүлек. Шәҗәрә төзибез (3сәг)** | | |
| **32** | “ Буыннарны бәйләп торган нәсел җебем өзелмәсме?!” Шәҗәрәңне беләсеңме? | материал җыю | конфер. |
| **33** | Укучыларның нәсел шәҗәрәсе белән танышу. | әңгәмә | клуб |
| **34** | Проект яклау: “Кече Елга авылы гореф-гадәтләре һәм йола бәйрәмнәре” темасына татарча проект (2 төркем) Йомгаклау. “Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклыйбыз” дәрестән тыш эшчәнлеге миңа нәрсә бирде ? | чыгыш | проект |